ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Николаевка авыл җирлегенең Рус Каран торак пунктында
2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

14 ноябрь 2025 № 4

2025 елның 20 мартында кабул ителгән № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 һәм 69 маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлеге Рус Каран торак пунктында халык җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлеге Рус Каран торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВО зонасында хезмәт итүче гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Рус Каран торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (вак таш сатып алу һәм салу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Николаевка авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп халыкка игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Николаевка авыл җирлеге башлыгы Т.Р Фарсиев